ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.03.2019**

Зеленодольск шәһ.

**КАРАР**
**№ 572**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 февралендәге 384нче карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты административ-техник инспекциясе идарәсе»нең төзекләндерү өлкәсендә оештыру һәм муниципаль контроль уздыру буенча функцияләре» Муниципаль казна учреждениесенең Административ башкару регламентына үзгәрешләр кертү турында

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актларны үтәү өчен муниципаль контроль булдыру буенча тиешле эшне оештыру, дәүләт вәкаләтләрен тиешле закон тәртибендә бирелгәнне гамәлгә ашыру, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контроле (күзәтчелек) алып барганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» №294-ФЗ Федераль закон положениеләрен һәм Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында Кодексын гамәлгә ашыру максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 февралендә 384нче карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты административ-техник инспекция идарәсе»нең төзекләндерү өлкәсендә оештыру һәм контроль уздыру буенча функцияләре» Муниципаль казна учреждениесенең Административ башкару регламенты кушымтасына ярашлы рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» Муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитетының

2019 елның 7 мартындагы

572нче карарына кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты административ-техник инспекция идарәсе»нең төзекләндерү өлкәсендә оештыру һәм контроль уздыру буенча функцияләре» Муниципаль казна учреждениесенең Административ башкару регламентына үзгәрешләр

1. Административ регламентның «III. Мәҗбүри таләпләрне бозу профилактикасына юнәлтелгән чаралар оештыру һәм уздыру» III бүлеген яңа редакциядә бирергә:

**«III. Мәҗбүри таләпләрне бозу профилактикасына юнәлтелгән чаралар оештыру һәм уздыру**

3.1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуларны, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозуга китергән сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны кисәтү максатыннан чыгып, «Идарә» ел саен алар тарафыннан расланган бозулар профилактикасы программасына ярашлы рәвештә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр бозу профилактикасы буенча чаралар уздыра.

3.2. Муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр бозу профилактикасы максатыннан чыгып, «Идарә»:

- дәүләт контроле (күзәтчелек), муниципаль контроль предметын һәм шулай ук ярашлы норматив хокукый актлар текстлары үтәлешен бәяләгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрдә, мәҗбүри таләпләрдә булган норматив хокукый актлар яисә аларның аерым өлешләренең исемлеген муниципаль контрольнең һәр төре өчен аларны рәсми сайтта http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштыруны тәэмин итә;

- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр үтәү буенча кулланманы эшләү һә бастырып чыгару, семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшен һәм башка ысуллар кулланып мәгълүматлаштыруны алып бара. Муниципаль актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр үзгәргән очракта, муниципаль актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр билгели торган яңа норматив хокукый актлар эчтәлеге, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр үтәүне үзләштерүгә һәм тәэмин итүгә юнәлтелгән кирәкле оештыру, техник чараларны уздыру турында тәкъдимнәр, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның гамәлгә кертелү сроклары һәм тәртибе турында комментарийлар әзерли һәм тарата;

- муниципаль контроль, дәүләт контроле (күзәтчелек) эшчәнлегенә ярашлы өлкәсендә (елга бер тапкырдан ким түгел) практиканы берләштерү һәм ярашлы берләштерүләрне «Интернет» челтәре рәсми сайтларында шундый бозуларны булдырмау максатыннан чыгып, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр кабул итәргә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән муниципаль хокукый актлар белән

билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр бозуларның еш очрый торган очракларын күрсәтеп урнаштыра;

- Административ регламентның 3.3нче пунктына, 3,5нче пунктына ярашлы, әгәр дә андый тәртип федераль закон белән билгеләнмәгән булса, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр бозуның мөмкин булмавы турында кисәтү бирә.

3.3. Әгәр дә ул федераль закон белән билгеләнмәгән булса, «Идарәнең» юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән элемтәгә кермичә алып барган контроль буенча чаралар гамәлгә ашыру барышында алынган муниципаль актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр бозу билгеләре турында яисә әзерләнә торган тәртип бозулар, яисә килгән гаризаларда һәм мөрәҗәгатьләрдә булган (авторы билгеле булмаган гаризалар һәм мөрәҗәгатьләрдән тыш), дәүләт власте, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм информация чараларыннан килгән мәгълүматларда гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кергән бик кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни кыйммәткә ия булган һәм милли китапханә фонды составына кергән документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян салырга, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуга китерергә яисә янау куркынычы тудырырга мөмкин булган расланган мәгълүматлар булмаса, “Идарә” юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтү игълан итә, һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә, һәм бу хакта кисәтүдә билгеләнгән срокта “Идарәгә” хәбәр итәргә кирәклеген җиткерә.

3.4. Муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтүдә ярашлы муниципаль актлар белән билгеләнгән ярашлы таләпләр, мәҗбүри таләпләр, аларны караган норматив хокукый акт, шулай ук юридик затның, шәхси эшмәкәрнең нинди конкрет гамәлләре (эшләмәве) бу таләпләрне бозуга китерергә мөмкин булуы турында күрсәтмәләр булырга тиеш. Муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтүгә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча юридик зат, шәхси эшмәкәр кабул иткән белешмәләрдән тыш, юридик зат, шәхси эшмәкәр таләпләре кертелми.

3.5. Муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне, мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү тәртибе, юридик зат, шәхси эшмәкәрнең мондый кисәтүгә каршы килүе һәм аларны карау тәртибе, шундый кисәтүне үтәү турында белдерү кәгазе тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3.6. Муниципаль контрольнең аерым төрләренең оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе “Идарә” тарафыннан зыян китерүне, табигый һәм техноген характерда гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтүгә юнәлтелгән махсус профилактик чаралар буларак алып барылырга мөмкин.

3.7. Россия Федерациясе Хөкүмәте муниципаль актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр бозу профилактикасы буенча чараларга муниципаль контроль органнары, дәүләт контроле органнары эшен оештыруга гомуми таләпләр билгеләргә хокуклы.

2. 4.1нче пунктның 1нче өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:
Муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләр үтәлеше буенча юридик затның һәм шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге турында мәгълүматны федераль законнарга ярашлы һәм шуларга ярашлы Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына ярашлы “Идарәгә” шундый затлар биргән (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларын куллану юлы белән) мәгълүмат аша күзәтү яисә ул “Идарә” тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә федераль законнар һәм аларга ярашлы Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән каралмаган бурычлар куймыйча гына алынырга мөмкин (шул исәптән ведомствоара мәгълүмат элемтәсе кысасында).
3. 7.4нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:
Әгәр дә юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кергән бик кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни кыйммәткә ия булган һәм милли китапханә фонды составына кергән документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян салынса яисә салынырга тиеш булса, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуга китерергә яисә янау куркынычы тудырырга мөмкин булса, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш чыгып тикшерү уздырыла башлавы турында хәбәр итү таләп ителми.
4. 8.4нче пунктның 4нче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:
- һәр планлы тикшерүнең башлануы һәм сроклары.

5. 9.2.11нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:
Әгәр дә юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кергән бик кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни кыйммәткә ия булган һәм милли китапханә фонды составына кергән документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян салынса яисә салынырга тиеш булса, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуга китерергә яисә янау куркынычы тудырырга мөмкин булса, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш чыгып тикшерү уздырыла башлавы турында хәбәр итү таләп ителми.

6. 9.4.3нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:
Боерыкта яисә әмердә тикшерү уздыру турында күрсәтелә:
1) муниципаль контроль органының исеме, шулай ук муниципаль контрольнең төре (төрләре);
2) тикшерү уздыруга куелган вазифадагы затның яисә вазифадагы затларның, шулай ук тикшерү уздыруга җәлеп ителгән экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы;
3) тикшерү уздырыласы юридик затның исеме яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, юридик затларның урнашкан урыны адресы (аларның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләренең) яисә шәхси эшмәкәрнең фактта эшчәнлек алып барган урыны;
4) тикшерүнең максаты, бурычлары, предметы һәм аны уздыру срогы;
5) тикшерү уздыруның хокукый нигезләмәләре;

6) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр мәҗбүри таләпләр, шул исәптән, әгәр дә планлы тикшерү барышында тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) кулланылса, тикшерү кәгазе реквизитлары;

7) тикшерү уздыруның максатына һәм бурычына ирешү өчен кирәкле чаралар исемлеге һәм уздыру сроклары;

8) муниципаль контроль алып баруга административ регламентлар исемлеге;

9) юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү уздыру һәм максатка ирешү өчен күрсәтүгә кирәкле документлар исемлеге:

- юридик затны дәүләт теркәве турында кенәгә;

- устав;

-юридик затлар бердәм реестрыннан өземтә;

- юридик затны җитәкче вазифасына, тирәлекне саклау, төзекләндерү, беркетелгән территорияне җыештыру, тышкы информацияне, рекламаны урнаштыру, файдалану һәм тоту өчен җаваплы ваифадагы затны билгеләү һәм вазифаи инструкцияләр (бурычлар) турында әмер ;

- юридик затның законлы вәкиле вазифасына билгеләү турында әмер;

- планлы тикшерү барышында юридик затның мәнфәгатьләрен күрсәтү хокукына ышаныч язуы;

- юридик зат вәкилләренең, җаваплы затларның шәхесләрен ачыклаучы документлары (паспорт) үзләре белән булырга һәм күрсәтергә тиешләр;

- производство структурасы;

- төп хисапчы исәп-хисапларыннан өземтә (01) (биналар, корылмалар, транспорт);

- юридик затның балансындагы транспорт чаралары турында белешмә, һәр техника тибы буенча уртача еллык йөрү турында белешмә;

- техник хезмәт күрсәтүгә килешү/накладнойлар, счет-фактуралар күчермәләре, автотранспорт чаралары ремонты;

- банк реквизитлары;

- керү төркемен кертеп, шул исәптән максатчан билгеләнешен раслаган шәхси милектә, арендада булган файдаланылган бинага проект документациясе;

- бина хуҗасы, арендага алучысы турында белешмәләр кертелгән хокукны билгеләгән документлар;

- бинаның фасады ягына үзгәрешләр кертүгә рөхсәт биргән документация;

-бинаны файдалануга тапшыру акты;

- биналарга, йортларга, җир участокларына милек хокукын яисә законлылыгын раслаган документлар;

- тышкы информацияне,рекламаны урнаштыруга рөхсәт биргән документация;

- юридик затның калдыклары барлыкка килүе турында белешмәләр, норматив калдыклар барлыкка килү һәм аларны урнаштыруга лимит проекты турында;

- ТБОны чыгару һәм утильләштерүгә килешү;

- калдыкларга мөнәсәбәт өлкәсендә исәп формасы;

- калдыклар барлыкка килү, куллану, зарарсызландыру һәм урнаштыру турында хисаплылык;

- юридик зат территориясендә калдыкларны җыю һәм вакытлыча саклау өчен мәйданчык урнаштыруның план-схемасы;

- калдыкларны башка оешмаларга тапшыру яисә үз производсволарында аларны кабат куллануны раслаган документлар:

1) тузган авторезина (модель), данә,

2 тотылган аккумуляторлар (тип), данә,

3) тотылган майлар (марка), т.,

4) кара металл ватыклары – т.,

5) төсле металл ватыклары – т.,

6) тотылган терекөмешле лампалар (ЛБ. ДРЛ) –т.,
7) макулатура, картон, төрү материаллары – т.,
8) полиэтилен пленка калдыклары һәм башка полимерлар – т.,
9) пыяла ватыгы – т.
10) предприятие хезмәткәрләренең уртача исемлеге саны – кеше, шул исәптән аерым күрсәтергә: эшчеләр, хезмәткәрләр – кеше, мәҗбүри административ ялда булган хезмәткәрләр – кеше;
11) предприятиенең еллар буенча эш вакыты фонды – эш көннәре, шул исәптән аерым күрсәтергә: эшчеләр өчен – көннәр, һәм хезмәткәрләр өчен дә – көннәр;
12) калдыкларны утильләштерүне, яңадан эшкәртүне, икенче тапкыр куллануны, полигонга чыгаруны, чыгару графигын раслаучы документлар;
13) сыек калдыкларны утильләштерүгә, коллектор булганда җаваплылык зонасын бүлү планы белән юынтык суларны кабул итүгә килешү, җаваплы затка файдалануны беркетү турында әмер, вазифа инструкциясе (вазифалары);
14) фасад, төзекләндерү паспорты;
15) җир эшләренә ордерлар;
16) җир эшләре башкарганнан соң төзекләндерүне торгызу буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты.
-тикшерү уздыруны башлау һәм тәмамлау датасы;
- муниципаль контроль органы җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының күрсәтмәсе яисә боерыгының типовой формасы белән каралган башка белешмәләр.

7. 9.4.23нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:
Тикшерү уздырганда юридик затның, шәхси эшмәкәрнең муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм таләпләрне бозулары ачыкланса, тикшерү уздырган «Идарә»нең вазифаи затлары Россия Федерациясе законнары белән каралган вәкаләтләр кысасында эшләргә тиеш:
- юридик затка, шәхси эшмәкәргә гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кергән бик кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни кыйммәткә ия булган һәм милли китапханә фонды составына кергән документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян салынуны кисәтү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтү һәм шулай ук федераль законнар белән каралган башка чаралар буенча чаралар уздыру турында һәм аларны төзәтү срокларын күрсәтеп ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында предписание бирергә;
- гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), Россия Федерациясе Музей фонды составына кергән бик кыйммәтле, шул исәптән уникаль музей әйберләренә һәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фонды документларына, аерым тарихи, фәнни, мәдәни кыйммәткә ия булган һәм милли китапханә фонды составына кергән документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян салынуны кисәтү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыгуны кисәтү, ачыкланган бозуларны юкка чыгаруга контроль буенча һәм шулай ук ачыкланган бозуларны булдыруга юл куйган җаваплы затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә.»;

8. 12.2нче пунктта.:

12.2нче пунктның 2нче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:
- шикаятьтә мөрәҗәгать җибәрүченең фамилиясе (исеме) яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы булмау;
2) 12.2нче пунктның 5нче пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:
- әгәр дә гражданинның язма мөрәҗәгатендә элек җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле язма җаваплар берничә тапкыр бирелгән булса, һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа исбатлаулар һәм хәлләр китерелмәсә, дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазифадагы зат яисә шул затның вәкиле чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсезлеге турында һәм әлеге мәсьәлә буенча гражданин белән, әгәр дә әлеге мөрәҗәгать һәм алдан җибәрелгән мөрәҗәгать берүк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә берүк вазифадагы затка җибәрелгән булса, язышуны туктату турында карар чыгарырга хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгать җибәргән гражданинга хәбәр ителә.

9. 12.6нчы пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:
Шикаять бирүченең язма (электрон) формасында түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- гражданин үзенең язма мөрәҗәгатендә язма мөрәҗәгать җибәрелгән дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының мәҗбүри рәвештә исеме, яисә ярашлы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булганда), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы, мөрәҗәгатьнең кире адресы турында уведомление, тәкъдимнең, гаризаның һәм шикаятьнең чын асылы, имзасы һәм датасы булырга тиеш.

- гражданин исбатлауларын расларга кирәк булса, язма мөрәҗәгатенә документлар һәм материаллар яисә аларның күчермәләрен беркетә.

- дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазифадагы затка электрон документ буларак килгән мөрәҗәгать 2005 елның 2 маендагы 59нчы ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатендә гражданин мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен (соңгысы – булганда), җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресын, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында уведомление күрсәтергә тиеш. Гражданин мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада беркетергә хокуклы.

10.12.9нчы пунктның 4нче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:
Мөрәҗәгатькә җавап язма формада җирле үзидарә органына яисә вазифадагы затка килгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада һәм электрон документ формасында җирле үзидарә органына яисә вазифаданы затка килгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ формасында җибәрелә. Болардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазифадагы затка килгән тәкъдимнәрдән, гаризадан һәм дәгъвадан торган мөрәҗәгать, аерым затлар мәнфәгатенә кагылган, аерым алганда кайбер затларга чыгарылган суд карарларына дәгъва белдерелгән мөрәҗәгатькә, шул исәптән суд карарына дәгъва белдерү тәртибен аңлаткан җавап Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин http://zelenodolsk.tatarstan.ru».